КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 13 август г.Казань № 651

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы грантларын бирүгә конкурслар үткәрү буенча республика комиссиясе турында» 2022 ел, 15 июнь, 557 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы грантларын бирүгә конкурслар үткәрү буенча республика комиссиясе турында» 2022 ел, 15 июнь, 557 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 30 гыйнвар, 78 нче; 2023 ел, 22 март, 324 нче; 2023 ел, 13 июль, 828 нче; 2023 ел, 28 декабрь, 1709 нчы; 2024 ел, 22 май, 355 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы Рәисе грантларын бирүгә конкурслар үткәрү буенча республика комиссиясе турында»

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Президентының «Граждан җәмгыятен үстерүгә бирелә торган Татарстан Республикасы Рәисе грантлары турында» 2021 елның 29 декабрендәге 1002-ПУ номерлы Указын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 пунктта татар текстында «грантларын» сүзе алдына «Рәисе» сүзенә алмаштырырга;

2 пунктта:

икенче абзацта татар текстында «грантларын» сүзе алдына «Рәисе» сүзенә алмаштырырга;

өченче абзацта татар текстында «грантларын» сүзе алдына «Рәисе» сүзенә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы грантларын бирүгә конкурслар үткәрү буенча республика комиссиясе турындагы нигезләмәдә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданлык җәмгыятен үстерүгә Татарстан Республикасы Рәисе грантларын бирүгә конкурслар үткәрү буенча республика комиссиясе турында нигезләмә»;

1.1 пунктта татар текстында «грантларын» сүзе алдына «Рәисе» сүзенә алмаштырырга;

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Республика комиссиясе Татарстан Республикасы Президентының «Граждан җәмгыятен үстерүгә бирелә торган Татарстан Республикасы Рәисе грантлары турында» 2021 елның 29 декабрендәге ПУ-1002 номерлы Указы белән расланган Граждан җәмгыятен үстерүгә бирелә торган Татарстан Республикасы Рәисе грантлары турындагы нигезләмәнең 2 пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча эшчәнлек алып баручы, социаль әһәмиятле проектларны һәм кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау өлкәсендәге проектларны гамәлгә ашыручы коммерциягә карамаган оешмаларга (алга таба – конкурста катнашучы) грантлар бирүгә конкурслар уздыру максатларында төзелә.»;

әлеге карар белән расланган Гражданлык җәмгыятен үстерүгә бирелә торган Татарстан Республикасы грантларын бирүгә конкурслар үткәрү буенча республика комиссиясе составы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданлык җәмгыятен үстерүгә бирелә торган Татарстан Республикасы Рәисе грантларын бирүгә конкурслар үткәрү буенча республика комиссиясе составы».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин